Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Керкәле авыл җирлегенең
Керкәле авылы торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре №1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге Керкәле авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлар тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тукай урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү:

-Керкәле торак пунктында Совет урамы, Җәлил урамы янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру;

4) Ритуал хезмәтләрен һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру:

-Керкәле торак пунктындагы зират территориясендә (килешү буенча түләү) коры һәм чүп үләнен чабу, иске авия хәлендәгеагачларны кисү;

5) Ял вакытын оештыру өчен шартлар тудыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү:

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел»бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 447 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 223.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 223 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге составына керүче Керкәле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге Керкәле авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлар тыш,, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тукай урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү:

-Керкәле торак пунктында Совет урамы, Җәлил урамы янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру;

4) Ритуал хезмәтләрен һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру:

-Керкәле торак пунктындагы зират территориясендә (килешү буенча түләү) коры һәм чүп үләнен чабу, иске авирия хәлендәгеагачларны кисү;

5) Ял вакытын оештыру өчен шартлар тудыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү:

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел»бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру сораулары буенча карарны кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет урамы, 93 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И.Бигманов